РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Мәктәп урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

24.04.2019 № 23

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында**

“ Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатында, Татарстан республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 14.06.2011 елгы №24 “Җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында” карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/korsabash/, җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы: А.Р.Гыймадиев

Курсабаш авыл җирлеге
башкарма комитетының
24.04.2019 елгы №23
карары белән РАСЛАНГАН

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелүче дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеге

| | |
|---|---|
| 1 | Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару |
| 2 | Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау |
| 3 | Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышанычнамәләрне раслау |
| 4 | Белешмәләр (өземтәләр) бирү |
| 5 | Агачлар яки куаклыкларны кисәргә, төпләргә яки утыртырга рөхсәт бирү |
| 6 | Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу |
| 7 | Муниципаль торак фондыннан гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү |
| 8 | Муниципаль торак фондындагы торак урыннарын гражданнарга хезмәт торак урынын найм шартнамәләре буенча бирү |
| 9 | Төзелеп беткән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлекләре бирү |
| 10 | Торак төзелеше максатларында аны комплексы үзләштерү өчен муниципаль милектә булган җирләрдән җир кишәрлеген арендалау шартнамәләрен төзү хокукын сату буенча торглар оештыру һәм үткәрү |
| 11 | Күчемсез милек объектларына муниципаль милек реестрыннан өземтә бирү |
| 12 | Җирлектәге муниципаль милектәге биналарны, корылмаларны һәм торак булмаган биналарны арендага бирү |